Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге Советы

КАРАР

3 сентябрь 2021 ел № 28

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 апрелендәге 16 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советының элегрәк 2021 елның 28 апрелендәге 16 номерлы карары беләгн расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне закон таләпләренә туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Сәләнгеш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Советының 2021 елның 28 апрелендәге 16 номерлы карары (алга таба - Нигезләмә) белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3 статьясының 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Ачык тыңлауларга мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге Уставы (алга таба - Устав) проекты, шулай ук әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проекты, уставны әлеге норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (устав) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш;

2) Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясе проекты;

4) Тавыш бирү юлы белән яисә гражданнар җыеннарында билгеләнгән "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеген үзгәртеп кору өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Сәләнгеш авыл җирлеге халкының ризалыгын алу таләп ителүче мәсьәләләрдән тыш, Нурлат муниципаль районының

Сәләнгеш авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре.

Генераль план проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проектларына, территорияне планлаштыру проектларына, территорияне ызанлау кагыйдәләренә, территорияне төзекләндерү кагыйдәләренә, проектларына күрсәтелгән документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектларга, җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның рөхсәт ителгән төренә яисә рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан читкә тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирү турындагы карарларның проектларына, җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның бер төрен һәм мондый файдалануның башка төрен үзгәртү мәсьәләләренә, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча расланган кагыйдәләр булмаган очракта, гавами тыңлаулар яисә шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә җәмәгать фикер алышулары уздырыла.

Җирлекнең генераль планы проектлары буенча иҗтимагый фикер алышуларны, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 28 маддәсендә китерелгән.

Иҗтимагый фикер алышулар әлеге Нигезләмәнең гавами тыңлаулар өчен билгеләнгән статьяларын исәпкә алып үткәрелә.».

1.2. Нигезләмәнең 5нче статьясында 5.4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

1.3. 6 статьяның 6.3 пунктындагы 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) даими яисә вакытлыча теркәлүе булган җирлектә яшәүчеләр;».

1.4. Нигезләмәнең 6нчы статьясында 6.6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

1.5. Нигезләмәнең 13 статьясын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга һәм җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Сәләнгеш авыл җирлеге
Советы рәисе А.Н. Пинин